**Казан шәһәре Думасының**
**2024 елның 18 декабрендәге 8-35 номерлы карары**

**Казан шәһәре Думасының «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 44 статьясы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 82 статьясы нигезендә Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Казан шәһәре Думасының «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр кертү турында»гы карары проектын (1 номерлы кушымта) хупларга һәм фикер алышуга, шул исәптән ачык тыңлауларга чыгарырга.

2. Казан шәһәре Думасының «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр кертү турында»гы карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен (2 номерлы кушымта) расларга.

3. Казан шәһәре Думасының 2018 елның 6 июнендәге 7-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә ачык тыңлаулар һәм җәмәгатьчелек белән фикер алышулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә 2025 елның 21 гыйнварында 14:00 сәгатьтә Казан шәһәре, Бауман урамы, 62/9 йорт адресы буенча (Казан шәһәренең «Мәгариф хезмәткәрләре йорты» муниципаль бюджет учреждениесе) Казан шәһәре Думасының «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»гы карары проекты (алга таба – карар проекты) буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

4. Карар проекты буенча ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар, ачык тыңлаулар үткәрү көненә кадәр җиде көннән дә соңга калмыйча, Казан шәһәре, Кремль урамы, 5 йорт, 503 бүлмә (эш

көннәрендә 9.00 дән 18.00 гә кадәр [төшке ял 12.00 дән 13.00 гә кадәр]; тел. 299-14-95) адресы буенча кабул ителә дип билгеләргә.

5. Йөкләргә:

5.1. Казан шәһәре Думасы аппаратына карар проекты буенча тәкъдимнәр кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итүне;

5.2. Тәкъдимнәр кертү максатыннан, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына тармак һәм территориаль структур бүлекчәләрдә карар проектын карап тикшерүне оештыруны;

5.3. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына һәм Казан шәһәре Думасы аппаратына карар проекты буенча ачык тыңлаулар уздыруны тәэмин итүне;

5.4. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасарына карар проекты буенча ачык тыңлауларда рәислек итүне;

5.5. Казан шәһәре Думасының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә:

- карар проекты буенча ачык тыңлауларда төп доклад белән чыгыш ясау өчен докладчы билгеләүне;

- ачык тыңлауларда әйтелгән һәм аны тикшерү барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерүне һәм карар проектын Казан шәһәре Думасына карап тикшерүгә кертүне.

6. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның 6 пунктын үтәгәннән соң бер көннән дә соңга калмыйча әлеге карарны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштырырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2024 елның 18 декабрендәге
8-35 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Думасының «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»гы карары проекты**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 28 статьясындагы 3 өлеше, 44 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 82, 83, 84 статьялары нигезендә Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Думасының 2006 елның 8 июнендәге 5-9 номерлы, 2007 елның 16 августындагы 7-19 номерлы, 2008 елның 26 июнендәге 15-31 номерлы, 2009 елның 29 апрелендәге 16-40 номерлы, 2010 елның 10 мартындагы 11-48 номерлы, 2010 елның 8 октябрендәге 2-54 номерлы, 2010 елның 6 декабрендәге 13-2 номерлы, 2011 елның 24 октябрендәге 14-8 номерлы, 2012 елның 19 апрелендәге 9-13 номерлы, 2013 елның 13 февралендәге 15-20 номерлы, 2013 елның 25 декабрендәге 16-28 номерлы, 2014 елның 25 июлендәге 16-34 номерлы, 2015 елның 4 мартындагы 30-41 номерлы, 2015 елның 7 сентябрендәге 13-45 номерлы, 2016 елның 20 апрелендәге 16-6 номерлы, 2017 елның 25 февралендәге 43-13 номерлы, 2017 елның 27 сентябрендәге 7-20 номерлы, 2018 елның 17 апрелендәге 21-25 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге 16-30 номерлы, 2019 елның 18 апрелендәге 14-33 номерлы, 2020 елның 28 февралендәге 14-38 номерлы, 2020 елның 21 октябрендәге 8-2 номерлы, 2021 елның 29 июнендәге 4-7 номерлы, 2022 елның 15 апрелендәге 18-13 номерлы, 2022 елның 22 ноябрендәге 17-18 номерлы, 2023 елның 14 июнендәге 4-23 номерлы, 2024 елның 26 апрелендәге 21-29 номерлы, 2024 елның 7 августындагы 5-31 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны, дәүләт теркәвен узганнан соң, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыкканнан соң, 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә торган карарның кушымтасының 2 өлешеннән тыш, 2025 елның 1 мартыннан гамәлгә керә торган 5 өлешенең 5.2 пунктының 5.2.1, 5.2.2, 5.2.3 пунктчалары, 5.4 пунктының 5.4.1, 5.4.2, 5.4.3 пунктчаларыннан тыш, гамәлгә керә дип билгеләргә.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»гы карарына кушымта

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр**

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 8 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 46 пункт өстәргә:

«46) хуҗалык кенәгәләрендә 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында»гы федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу».

2. 9 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Башкарма комитет тиешле вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү максатыннан Казан шәһәренә бирелгән субвенцияләр чикләрендә Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен, Татарстан Республикасы вәкаләтләрен башкару өчен җавап бирә».

3. 10 статьяны түбәндәге редакциядә бирергә:

«10 статья. Муниципальара хезмәттәшлек

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге түбәндәге формаларда муниципальара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра:

1) муниципаль берәмлекләр берләшмәләрендә әгъзалык;

2) муниципальара хуҗалык җәмгыятьләрен, муниципальара массакүләм мәгълүмат басма чарасы һәм челтәр басмасы булдыру;

3) коммерцияле булмаган оешмалар оештыру;

4) шартнамәләр һәм килешүләр төзү.

2. Муниципальара хуҗалык җәмгыятьләре Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең финанс чараларын, матди һәм башка ресурсларын берләштерү максатыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне бердәм хәл итү өчен башка муниципаль берәмлекләр белән гамәлгә куела.

3. Шәһәр Думасы автономияле коммерцияле булмаган оешмалар һәм фондлар рәвешендә Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең коммерцияле булмаган оешмаларын төзү турында карар кабул итәргә мөмкин.

4. Муниципальара хуҗалык җәмгыятьләре, коммерцияле булмаган оешмалар үз эшчәнлекләрен Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, башка

федераль законнар нигезендә башкаралар һәм җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә ия була алмыйлар.

5. Җирле үзидарә органнары муниципальара басма массакүләм мәгълүмат чарасын һәм челтәр басмасын гамәлгә куючыларның берсе була алалар».

4. 28 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бирергә:

«28 статья. Шәһәр Думасы вәкаләте

1. Шәһәр Думасының түбәндәге вәкаләтләре бар:

1.1. Казан шәһәре уставын кабул итү һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

1.2. Казан шәһәре бюджетын һәм аның үтәлеше турында хисапны раслау;

1.3. Салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару, аларны түләү буенча ташламалар билгеләү һәм аларны гамәлдән чыгару;

1.4. Казан шәһәренең социаль-икътисади үсеш стратегиясен раслау;

1.5. Казан шәһәре муниципаль милкендәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибен билгеләү;

1.6. муниципаль предприятиеләрне төзү, үзгәртеп оештыру һәм бетерү турында, шулай ук муниципаль предприятие һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү, федераль законнарда каралган очраклардан тыш, эшләр башкару турында карарлар кабул итү тәртибен билгеләү;

1.7. Казан шәһәренең муниципальара хезмәттәшлек оешмаларында катнашу тәртибен билгеләү;

1.8. Казан шәһәре җирле үзидарә органнары эшчәнлеген матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү тәртибен билгеләү;

1.9. Казан шәһәре җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазифаи затлары тарафыннан җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен үтәүне контрольдә тоту;

1.10. Шәһәр Думасы депутатларын сайлаулар көнен билгеләү;

1.11. Шәһәр Думасы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча Шәһәр Думасы Регламентын, башка хокукый актларны кабул итү;

1.12. Казан шәһәренең рәсми символларын һәм аларны рәсми куллану тәртибен билгеләү;

1.13. Казан шәһәренең бүләкләрен һәм мактаулы исемнәрен, аларны бирү тәртибен билгеләү;

1.14. Шәһәр Думасы депутатларын сайлаулар буенча сайлау округлары схемасын раслау;

1.15. җирле референдумны билгеләү;

1.16. Чикләрне үзгәртү, Казан шәһәрен үзгәртеп кору турында инициатива күрсәтү, Казан шәһәренең чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору, Казан шәһәре районнары чикләрен үзгәртү мәсьәләләре буенча халык фикерен ачыклау;

1.17. Казан шәһәренең чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору, Шәһәр Думасы депутатының мандатын кире кайтарып алу мәсьәләләре буенча тавыш бирүне билгеләү;

1.18. гражданнарның хокукый акт чыгару инициативасын гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

1.19. территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен, җирле бюджеттан кирәкле акчаларны бүлеп бирү, территориаль иҗтимагый үзидарә уставларын теркәү шартларын һәм тәртибен билгеләү;

1.20. ачык тыңлауларны, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм уздыру тәртибен билгеләү;

1.21. гражданнарның җыелышларын билгеләү һәм уздыру тәртибен, халыкның җыелышлары вәкаләтләрен билгеләү;

1.22. гражданнарның конференциясен (делегатлар җыелышын) билгеләү һәм уздыру, делегатларны сайлау тәртибен билгеләү;

1.23. Татарстан Республикасы законы нигезендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибен билгеләү;

1.24. конкурс нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет Җитәкчесен билгеләп кую, Башкарма комитет Җитәкчесе өчен контракт шартларының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлешен раслау, аның хезмәттән азат ителүен кабул итү;

1.25. Башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибен билгеләү, закон нигезендә конкурс комиссиясе әгъзаларын билгеләп кую;

1.26. Башкарма комитет Җитәкчесенең тәкъдиме буенча Башкарма комитет структурасын раслау;

1.27. Шәһәр Думасы аппаратын оештыру;

1.28. Контроль-хисап палатасының хокукый статусын булдыру һәм билгеләү;

1.29. гавами булмаган акционерлык җәмгыятьләре һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр рәвешендә муниципальара хуҗалык җәмгыятьләрен гамәлгә кую турында карарлар кабул итү;

1.30. автономияле коммерцияле булмаган оешмалар һәм фондлар рәвешендә коммерцияле булмаган оешмалар төзү турында карарлар кабул итү;

1.31. Казан шәһәренең генераль планын, территорияләрне планлаштыру документларын, Казан шәһәре территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау;

1.32. шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен билгеләү;

1.33. Казан шәһәренең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау һәм шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларына үзгәрешләр кертү;

1.34. Казан шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау;

1.35. муниципаль милектәге җир кишәрлегендә, бинада яисә башка күчемсез мөлкәттә реклама корылмасын урнаштыру һәм файдалануга шартнамә төзүгә сатулар (аукцион яисә конкурс) үткәрү формаларын билгеләү;

1.36. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукын гамәлгә ашыру;

1.37. муниципаль юл фонды төзү турында карар кабул итү (җирле бюджет турындагы карардан тыш);

1.38. муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибен билгеләү;

1.39. муниципаль махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибен билгеләү;

1.40. Казан шәһәренең юридик зат буларак төзелә торган җирле үзидарә органнары, башкарма комитет органнары турындагы нигезләмәләрне раслау;

1.41. бюджет мөнәсәбәтләре өлкәсендә контрольне законнар нигезендә гамәлгә ашыру;

1.42. биналарны, корылмаларны эксплуатацияләүгә карата Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәмәү турында, аларда авария очрагы барлыкка килү яисә аларның ишелү ихтималы турында биналар, корылмалар урнашкан урын буенча Казан шәһәре җирле үзидарә органына физик яисә юридик затлардан гаризалар алынган очракта, биналарга һәм корылмаларга тикшерү уздыру тәртибен раслау;

1.43. социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өч яклы комиссияләр турындагы нигезләмәләрне раслау;

1.44. Россия Федерациясе законнары нигезендә Казан шәһәре бюджеты акчалары хисабына инвестицион проектлар буенча муниципаль гарантияләр бирү тәртибен раслау;

1.45. халык дружинасы төзелергә мөмкин булган территориянең чикләрен билгеләү;

1.46. балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясен төзү, аның составын раслау;

1.47. 2021 елның 25 сентябрендәге 57-ТРЗ номерлы «2022 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем ала алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында»гы Татарстан Республикасы законында каралган җаваплылык чараларын депутатка карата куллану турында карар кабул итү тәртибен раслау;

1.48. инициативалы проектларны гамәлгә ашыру мөмкинлеге булган Казан шәһәре территориясе өлешен билгеләү тәртибен, инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу, карап тикшерү мөмкинлеге булган, шулай ук аларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибен, инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү өчен коллегиаль орган (комиссия) формалаштыру һәм аларның эшчәнлеге тәртибен, җирле бюджетка күчергән затларга (шул исәптән оешмаларга) кайтарылырга тиешле инициатив түләү суммаларын исәпләү һәм кире кайтару тәртибен билгеләү;

1.49. Казан шәһәре торак пунктының гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрелә торган территориясе чикләрен билгеләү;

1.50. мондый муниципаль программаларга үзгәрешләр кертү турында муниципаль программалар проектларын һәм тәкъдимнәрне Шәһәр Думасының норматив-хокукый актында билгеләнгән тәртиптә карап тикшерүне гамәлгә ашыру хокукы;

1.51. муниципаль контроль төрләре турындагы нигезләмәләрне раслау;

1.52. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 19 статьясы нигезендә җирле үзидарә органнарына тапшырылмаган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашуга аларның хокукын гамәлгә ашыру турында карар кабул итү;

1.53. муниципаль берәмлек башлыгын отставкага җибәрү турында карар кабул итү;

1.54. федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән шәһәр округларының вәкиллекле органнары компетенциясенә кертелгән башка

вәкаләтләр, шулай ук әлеге Устав һәм/яисә Шәһәр Думасының норматив хокукый актлары белән кертелгән вәкаләтләр».

5. 40 статьяда:

5.1. 1 өлешнең 1.25 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.25. Казан шәһәре ягыннан капитал салуларны саклау һәм аларга булышлык турында килешүләр төзү шартларын һәм тәртибен җайга сала торган муниципаль хокукый актлар кабул итә»;

5.2. 3 өлештә:

5.2.1. 3.20 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.20. Казан шәһәренең җылылык белән тәэмин итү чорына әзерлеген тәэмин итә, шул исәптән «Җылылык белән тәэмин итү турында»гы федераль законның 20 статьясында һәм җылылык чорына әзерлекне тәэмин итү кагыйдәләрендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үти һәм «Җылылык белән тәэмин итү турында»гы федераль законның 20 статьясындагы 1 өлешенең 2-6 пунктларында санап кителгән затлар тарафыннан җылыту чорына әзерлекне бәяләүне уздыру тәртибе нигезендә җылылык чорына әзерлекнең тәэмин ителешен бәяләүне үткәрә»;

5.2.2. түбәндәге эчтәлекле 3.24, 3.25 пунктлар өстәргә:

«3.24. 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы «Җылылык белән тәэмин итү турында»гы федераль законда билгеләнгән нигезләмәләрне исәпкә алып, Казан шәһәрен җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә авария хәлләре нәтиҗәләрен бетерү буенча гамәлләр тәртибен (планын) раслый һәм ел саен актуальләштерә (шул исәптән авария хәлләрен электрон модельләштерүне кулланып);

3.25. җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның, җылылык челтәре оешмаларының һәм җылылык челтәре булмаган җылылык челтәрләре хуҗаларының җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә авария хәлләре нәтиҗәләрен бетерү буенча гамәлләренең тәртибен (планнарын) килештерә»;

5.2.3. 3.24.-3.28 пунктларны 3.26.-3.30 пунктлар дип санарга;

5.3. 6 өлештә:

5.3.1. 6.18 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«6.18. халыкка хәбәр җиткерү муниципаль системаларын, саклау корылмаларын һәм гражданнар оборонасының башка объектларын төзи, реконструкцияли һәм даими рәвештә файдалануга әзерлек хәлендә тота»;

5.3.2. 6.22 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«6.22. халыкка вакытында хәбәр җиткерүне тәэмин итә һәм гамәлгә ашыра»;

5.4. 16 өлештә:

5.4.1. 16.8 пунктта «гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында урнашкан парковкалардан (парковка урыннарыннан) түләүле нигездә файдаланган өчен» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.4.2. 16.17 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«16.17. гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәте оештыруны, шул исәптән юл хәрәкәтен мониторинглауны да гамәлгә ашыра»;

5.4.3. 16.19 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«16.19. җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын урнаштыруны, алмаштыруны, сүтүне һәм карап тотуны тәэмин итә»;

5.5. 17 өлештә:

5.5.1. түбәндәге эчтәлекле 17.19 пункт өстәргә:

«17.19. 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында»гы федераль закон нигезендә хуҗалык кенәгәләрендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә ала»;

5.5.2. 17.19 пунктны 17.20 пункт дип санарга;

6. 56 статьяның 9 өлешендәге беренче абзацта «, һәм, әгәр законнарда башкасы каралмаган булса, аларны Реестрга керткәннән соң үтәү өчен җибәрелә» сүзләрен төшереп калдырырга.

7. 66 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«4. Казан шәһәре җирле үзидарә органнары электр энергетикасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда муниципаль милектә торучы электр челтәре хуҗалыгы объектларын Татарстан Республикасы чикләрендә эш итүче система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмасына яисә территориаль челтәр оешмасына түләүсез биләүгә һәм файдалануга тапшыралар.

8. 78.1 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 6, 7 пунктлар өстәргә:

«6) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең системалы рәвештә түбәнәюе;

7) аңа чит ил агенты статусы бирелгәндә».

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**

Казан шәһәре Думасының
2024 елның 18 декабрендәге
8-35 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Думасының «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»гы карар проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу һәм гражданнарның аның турында фикер алышуда катнашу тәртибе**

1. Казан шәһәре Думасының «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»гы карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу һәм гражданнарның аның турында фикер алышуда катнашу тәртибе Казан шәһәре халкының 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 44 статьясы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 82 статьясы нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый акт проекты буенча фикер алышуда катнашуга хокукын үтәү максатыннан эшләнде.

2. Казан шәһәре Думасының «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»гы карар проектына (алга таба – карар проекты) тәкъдимнәр һәм искәрмәләр гражданнар тарафыннан, әлеге Тәртипнең 2 номерлы кушымтасындагы форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкны теркәп, әлеге Тәртипнең 1 номерлы кушымтасындагы форма буенча кертелә.

3. Карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча почта аша җибәрелә яки кулга тапшырыла: Казан шәһәре Думасы, 420014, Казан шәһәре, Кремль урамы, 5 йорт, 503 кабинет, электрон почта аша (npu.kazan@tatar.ru).

4. Карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр әлеге карар басылып чыккан көннән алып карар проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру көненә кадәр эш көннәрендә һәм карар проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру көнендә 09:00 дән 18:00 гә кадәр (төшке аш 12:00 дән 13:00 гә кадәр) кабул ителә.

5. Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр Казан шәһәре Думасы аппараты

хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм Казан шәһәре Думасының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә карап тикшерүгә тапшырыла.

6. Карар проектына кертелә торган төзәтмәләр Казан шәһәре Думасының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясе тарафыннан карап тикшерелә.

7. Карап тикшерү йомгаклары буенча карар проекты эшләнеп бетә һәм Казан шәһәре Думасына тапшырыла.

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**

Казан шәһәре Думасының
«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге
Уставына үзгәрешләр кертү турында»гы
карар проекты буенча тәкъдимнәрне
исәпкә алу тәртибенә
1 номерлы кушымта
(Форма)

**Казан шәһәре Думасына**

**Казан шәһәре Думасының «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр кертү турында»гы карар проекты буенча кертелә торган тәкъдимнәр һәм искәрмәләр**

Төзәтмә авторы: ______________________________________________________________________.
*(фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

Яшәү (теркәлү) урыны: ______________________________________________.
Эш (уку) урыны: _____________________________________________________________________.
Телефоны: ______________________________________.

| Карар проектының статьясы, пункты, пунктчасы | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмә кертелгән текст проекты |
|---|---|---|---|
| | | | |

«___»_____________ ______ ел

_________/______________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**

Казан шәһәре Думасының
«Казан шәһәре муниципаль
берәмлеге Уставына үзгәрешләр
кертү турында»гы карар проекты
буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу
тәртибенә
2 номерлы кушымта
(Форма)

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык**

Мин, ____________________________________________________________,
(шәхси мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме, атасының исеме)
_______________________________________________ адресы буенча теркәлгән,
шәхесне таныклаучы документ: ____________________________________________
________________________________________________________________________,
(документның исеме, номеры, документны бирү көне һәм аны биргән орган турында белешмәләр)
2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Казан шәһәре Думасының «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»гы карары проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү максатыннан Казан шәһәре Думасына (420014, Казан шәһәре, Кремль урамы, 5 йорт) минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә, атап әйткәндә: фамилияне, исемне, атамның исемен, яшәү (теркәлү) урынын, эш (уку) урынын, телефон номерын эшкәртүгә, ягъни 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы Федераль законның 3 статьясындагы 3 пунктында каралган гамәлләрне башкаруга, шулай ук, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда, мондый мәгълүматны өченче затларга тапшыруга ризалык бирәм.

Әлеге ризалык аны имзалаган көннән алып һәм аны язмача кире кайтарып алганчыга кадәр гамәлдә була.

______ елның «___»______________ ____________/_________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**